| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан<br>Глава Старомензелябашского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района** | **Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Иске Минзәләбаш<br>авыл җирлеге башлыгы** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел 9 ноябрь № 4

Татарстан Республикасы Сарман
муниципаль районы Иске Минзәләбаш
авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылында
2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1.Иске Минзәләбаш авылы гражданнарның 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне 2020 елның 21 ноябрենә 10 сәгатькә Иске Минзәләбаш мәдәният йортында билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, I төркем инвалидлар; олы яшьтәге ялгыз гражданнар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлар; хөкем ителгәннәр; авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 200 сум күләмендә узара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме?:

1) Иске Минзәләбаш торак пунктының Комсомол урамын ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, җәю,килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Иске Минзәләбаш торак пунктының урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

3) Иске Минзәләбаш торак пунктында Сабантуй бәйрәме үткәрү мәйданы территориясен төзекләндерү ( павильон сатып алу һәм урнаштыру, территорияне төзекләндерү өчен материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

4) Иске Минзәләбаш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, Өлкәннәр көне, 9 Май, инвалидлар көне, спорт ярышлары ) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

5) Авыл җирлеге чикләрендә аншлаг язуларын ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү);

6) Җәйге чорда Иске Минзәләбаш торак пунктында территорияне чабу (Беларусь -320.4 маркалы тракторга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, бензин белән эшли торган триммер сатып алу )

7) Иске Минзәләбаш торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларусь -320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

8) Иске Минзәләбаш торак пунктында чишмәләр территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу , юл салу, павильон сатып алу һәм урнаштыру, буяу, конструкцияләрне ремонтлау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

9) «Сарман» район газетасына некрологлар бирү

ӘЙЕ ЮК?»

3.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы А.Н.Габдрахманов